**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**

**муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2023 елның 9 июне 188№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 22 мартындагы « 2023 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын раслау турында»76 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ :

1. «2023 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Преамбулада Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 14 октябрендәге «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» ПУ-610 номерлы Әмере нигезендә эшләнгән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 06 декабрендәге ПУ-1115 номерлы Әмере, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 3 октябрендәге «2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру» федераль максатчан программасы турында» 864 номерлы карары нигезендә (2020 елның 16 маендагы 703 номерлы ред.) сүзләренә алмаштырырга;

Программа паспортында:

Программаны тормышка ашыру механизмы, аны тормышка ашыру барышын контрольдә тотуны һәм идарә итүне оештыру бүлегенең беренче абзацында 1999 елның 6 маендагы 97-ФЗ номерлы "Дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыруга конкурслар турында " гы 97-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 1997 елның 8 апрелендәге 305 номерлы Әмере белән расланган "Дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алуны оештыру турында нигезләмә"се сүзләрен төшереп калдырырга.

Программаның Ресурслар белән Тәэмин итү бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

«2023 елда Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» максатчан программасын финанслауның гомуми күләме: - 22575,5 мең сум»

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Җитәкче Р.Х.Морадымов

А.М. Әхмәтҗанова
88434620051